**СОВЕТ УРУСОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРЫС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«29» ноябрь 2021 ел № 2

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Урыс авыл җирлеге Урыс торак пунктында үзара салым кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Урыс авыл җирлеге Урыс торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1..Минзәлә муниципаль районының Урыс авыл җирлеге Урыс торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда 500 сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан, 1 төркем инвалидлар, балачактан инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш.

2.Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1. Авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, җәю) Урыс торак пунктында Мәктәп ур. 1, Дуслык ур. 66, адресы буенча, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) ;

2. Урыс торак пунктында чаралар оештыру һәм бәйрәмнәр үткәрү ( бүләкләр алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

3. Урыс торак пунктында юлларны грейдрлау, кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

4. Урыс торак пунктында җәйге чорда юл кырыйларын чабу (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

5.Урыс торак пунктында санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (чүплекләрне буртлау, чүп чыгару, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

6.Урыс торак пунктында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материаллар, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);

7.Урыс торак пунктында су алу скважинасына (су башнясы) тирән насос сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча түләү).

3.Җыен нәтиҗәләрен Урыс авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итергә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга http://menzelinsk.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында http://pravo.tatarstan. кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Урыс авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе: ____________ Аксюкова И. С .
(имза) (имзаны киңәйтү)